СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2021 елның 28 октябре № 12/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының, аның составына керүче авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 ст. һәм 29.4 ст., «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районын, аның составына керүче авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының инфраструктура үсеше һәм торак мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы,Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров

000733

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советының 2021 елның
28 октябрендәге 12/4 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районын, аның составына керүче авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1 бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының, аның составына керүче авыл җирлекләренең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районын, аның составына керүче авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары (алга таба - җирле нормативлар) муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге объектлары белән тәэмин ителешнең рөхсәт ителә торган минималь күрсәткечләренең: халыкны электр-, җылылык-, газ-, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәләренә, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына, физик культурага һәм массакүләм спортка, мәгарифкә, сәламәтлек саклауга, территорияне төзекләндерү объектларына, җирле әһәмияттәге башка объектларга һәм район халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан файдалана алуының мөмкин булган максималь күләменең исәп күрсәткечләре җыелмасын билгели.

3. Җирле нормативларда кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең минималь исәп-хисап күрсәткечләре Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыруның республика нормативларындагы кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең исәп-хисап күрсәткечләренә караганда түбәнрәк була алмый.

4. Җирле нормативлар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) төп өлешне (муниципаль берәмлек халкы тарафыннан тәэмин ителешнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен һәм мондый объектларның муниципаль берәмлек халкы өчен максималь рөхсәт ителә торган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен);

2) шәһәр төзелеше проектлау нормативларының төп өлешендәге исәп-хисап күрсәткечләрен нигезләү буенча материаллар;

3) шәһәр төзелешен проектлау нормативларының төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен куллану кагыйдәләре һәм өлкәсе.

5. Әгәр җирле нормативларда аерым минималь исәп-хисап күрсәткечләре юк икән, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлау нормативлары

составында исәп-хисап күрсәткечләренең иң чик күрсәткечләре кулланылырга тиеш.

## 2 бүлек. ҖИРЛЕ НОРМАТИВЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ РАСЛАУ ТӘРТИБЕ

6. Җирле нормативларны әзерләү Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар үз эченә ала:

1) җирле нормативларда чагылдырылырга тиешле исәп-хисап күрсәткечләре исемлеге;

2) җирле нормативлар проектын әзерләү сроклары һәм күрсәтмәләре;

3) кызыксынган затларның җирле нормативлар проекты буенча тәкъдимнәрен җибәрү һәм карау тәртибе турында белешмәләр;

4) проектны финанслау шартлары һәм җирле нормативларны әзерләү буенча эшләрне оештыруның башка мәсьәләләре.

8. Җирле нормативларны әзерләү Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге (алга таба - вәкаләтле орган) мөстәкыйль рәвештә йә махсуслаштырылган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла, аны сайлап алу сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар нигезендә башкарыла.

9. Вәкаләтле орган:

1) җирле нормативлар проектын әзерләү буенча эшләрне оештыруны гамәлгә ашыра;

2) җирле нормативлар әзерләүгә техник бирем эшли;

3) кызыксынган затларның җирле нормативлар проекты буенча тәкъдимнәрен җыюны тәэмин итә;

4) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының (алга таба – район Советы) җирле нормативларны раслау турында яки аларга үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

10. Җирле нормативларны әзерләү түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарыла:

1) муниципаль берәмлекләр территориясендә халыкның социаль-демографик составы һәм халык тыгызлыгы;

2) муниципаль берәмлекләрнең комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнары һәм программалары;

3) җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәре

11. Шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә раслана.

12. Вәкаләтле орган әлеге нормативларны кабул итүдә кызыксынган оешмалар, дәүләт күзәтчелеге органнары, авыл җирлекләренең башкарма комитетлары белән (авыл җирлегенең җирле нормативлары проектын эшләгәндә) җирле нормативлар проектын килештерүне тәэмин итә.

Килештерүче оешмалар һәм органнар исемлеге гамәлдәге законнар нигезендә техник биремдә вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

Җирле нормативлар проектын килештерү срогы әлеге проектны килештерүгә алган көннән бер ай тәшкил итә.

Билгеләнгән вакытка килештерүче оешмалардан һәм органнардан җирле нормативлар проектына бәяләмәләр кертелмәгән очракта, әлеге проект килештерелгән дип санала.

13. Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» челтәрендә шәһәр төзелеше проектының җирле нормативлары проектын бастырып чыгаруны һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә расланырга ике айдан да ким булмаган вакыт эчендә бастырып чыгаруны тәэмин итә.

14. Вәкаләтле орган 10 пунктта күрсәтелгән срок узгач, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, җирле нормативлар проектын эшләп бетерә һәм аны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшыра.

Кергән тәкъдимнәр турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм мондый тәкъдимнәр белән килештерүнең (риза булмауның) нигезле булуын күрсәтү эшләнеп беткән җирле нормативлар проектына карата мәҗбүри кушымта булып тора.

15. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе аңа җирле нормативлар проектын тәкъдим иткәннән соң җиде көн эчендә әлеге проектны раслау өчен район Советына җибәрү яки җирле нормативлар проектын кире кагу һәм аны кабат тапшыру датасын күрсәтеп, эшләп бетерүгә җибәрү турында карар кабул итә.

16. Җирле нормативлар һәм җирле нормативларга кертелгән үзгәрешләр район Советы тарафыннан раслана.

17. Җирле нормативлар расланганнан соң биш көн эчендә вәкаләтле орган расланган җирле нормативларны шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системалаштыруны тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органына җибәрә.

18. Вәкаләтле орган расланган җирле нормативларны территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында күрсәтелгән нормативлар расланган көннән алып биш көннән дә артмаган срокта урнаштыруны тәэмин итә.

19. Җирле нормативларга үзгәрешләр кертү җирле нормативларны әзерләү һәм раслау өчен әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.